ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.04.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 989**

Зеленодольск муниципаль районының 2013-2016 елларда гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү программасы буенча күчерелгән йортларның коммуникацияләреннән өзелүе турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 31 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы авария хәлендәге күпфатирлы йортларның исемлеген раслау турында» 1553 номерлы карары, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 6 февралендәге «Зеленодольск муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 16 декабрендәге 3622 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программага үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 176 номерлы карары нигезендә, Россия Федерациясе Торак кодексына таянып, йортларның күчерелүен истә тотып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольск газ», «ЗВКС» АҖ, Идел буе бүлекчәсенең Зеленодольск ОКО - «Татэнергосбыт» ААҖ, «Зеленодольск җылылык челтәрләре предприятиесе» ҖЧҖ коммуникацияләрдән тиешле төрдәге авария хәлендәге торак йортларны өзәргә тәкъдим итәргә:
- Зеленодольск шәһәре, Гоголь ур., 16;
- Зеленодольск шәһәре, Мәскәү ур., 6;
- Зеленодольск шәһәре, Тургенев ур., 11;
- Зеленодольск шәһәре, Кызыл Тыкрык ур., 14;
- Зеленодольск шәһәре, Кызыл Тыкрык ур., 15;
- Зеленодольскшәһәре, Карл Маркс ур., 29;
- Новониколаевский п., Солидарная ур., 30;
- Норлат авылы, Якты ур., 1;
- Васильево штп, Куйбышев ур., 47.

2. «Зеленодольск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» МБУ әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән адреслар буенча торак урыннарының социаль наем шартнамәләрен өзәргә.

3. ««Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесенә билгеләнгән тәртиптә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән биналарны Зеленодольск шәһәренең муниципаль милек реестрыннан төшереп калдыруны тәэмин итәргә, күчерелгән йортлар урынына «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасына җир кишәрлекләрен тапшырырга.

4. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С. Анисимовка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы сайтында яисә «Зеленодольская правда» газетасында урнаштыру юлы белән бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Д.А. Сапожников